ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Мира, д.11А,пос.с-за "Мамадышский",
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛЫ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Мира ур., 11А нче йорт, "Мамадыш" совхозы
поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
"26" ноября 2019 г.

Карар
№ 102

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән, җирле референдумда кабул ителгән «24» ноябрь 2019 елдагы 1156 нче номерлы карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Кызыл Тау авыл җирлеге
Башкарма комитет
җитәкчесе Гыйззәтуллина В.Ә.

Татарстан республикасы
Мамадыш муниципаль районы,
Кызыл Тау авыл җирлеге
башкарма комитетының 2019
елның 26 нче ноябре 102 нче №
лы карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Кызыл Тау авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 2020 нчы елның 28 нче мартына кадәр, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына, көндезге уку формасында укыган студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, Россия Кызыл Армия сафларында хезмәт итүчеләрдән башка, һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а)вакытлыча эшсез калганда

б) эш буенча командировкада булганда

гражданнарга гариза нигезендә бер айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган белдерү гражданнар игътибарына муниципаль берәмлекнең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгару, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

6. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге лицевой счетына күчереләләр.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки

https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге
башкарма комитетының 2019
елның 26 нче ноябре 102 нче№
лы карарына 1 нче кушымта

Кызыл Тау авыл җирлеге
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында

БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № ______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_______________________________________________________________

Адрес:
_______________________________________________________________

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән, җирле референдумда кабул ителгән «25» ноябрь 2018 елдагы 1156 нче номерлы карарны гамәлгә ашыру максатыннан Сезгә 400 сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

Кабул итүче як банкы: ГРКЦ НБ РТ банка России г.Казань
БИК 049205001
Сч. № 40101810800000010001
Кабул итеп алучы: УФК по Республике Татарстан( Финансово-бюджетная палата Мамадышского муниципального района РТ)
ИНН 1626008921
КПП 162601001
КБК 60511714030100000180 ОКАТО 92638430
Түләүнең билгеләнеше : үзара салым

Җитәкче В.Ә. Гыйззәтуллина
М.У .

**----------------- кисеп алу сызыгы --------------**

Белдерү кәгазе №_____

Кызыл Тау авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне 400 сум күләмендә түләү турында

Түләүченең Ф.И.Ә.и.

______________________________________________

Адрес:

____________________________________________________________

Кабул ителде «__» _______________ 20__ ел.

________________________________

*(түләүченең имзасы)*

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм Кызыл Тау авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*